Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Борискино авыл җирлеге Яңа Әнҗерә авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

2019 елның 26 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 114 номерлы Әлки муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борискино авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 113 номерлы «Борискино авыл җирлеге» составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлегенең Яңа Әнҗерә авылында гражданнар җыенының 2019 елның 25 ноябрендәге 3 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлеге составына керүче Яңа Әнҗерә авылындагы гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

-авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тотуга, күперләрне ремонтлауга, МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтүгә, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алуга һәм килешү буенча түләү -220 сум;

-урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлауга , урам системасын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм ремонтлауга, су үткәрү челтәрләрен, су башнясын реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкаруга, урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлау өчен кирәкле материал сатып алуга, су башнясын буяуга, су анализы өчен чыгымнарга, су башнясын лицензияләү белән бәйле чыгымнарны каплауга - 120 сум;

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алуга, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләренә һәм урам утлары кулланылган энергиягә чыгымнарны түләүгә бәйле чыгымнарга–100 сум;

- чишмәләрне һәм күлләрне төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга-70 сум;

- каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм утильләштерү өчен кирәкле төзелеш материалы, инвентарь һәм җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарга, килешү буенча штаттан тыш хезмәт хакына-40 сум.

- зиратларны тотуга( төзелеш материаллары сатып алуга , килешү буенча хезмәт хакына һ. б.) бәйле чыгымнарга -50 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

-авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тотуга, күперләрне ремонтлауга, МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтүгә, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алуга һәм килешү буенча түләү -220 сум;

-урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлауга , урам системасын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм ремонтлауга, су үткәрү челтәрләрен, су башнясын реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкаруга, урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлау өчен кирәкле материал сатып алуга, су башнясын буяуга, су анализы өчен чыгымнарга, су башнясын лицензияләү белән бәйле чыгымнарны каплауга - 120 сум;

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алуга, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләренә һәм урам утлары кулланылган энергиягә чыгымнарны түләүгә бәйле чыгымнарга–100 сум;

– чишмәләрне һәм күлләрне төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга-70 сум;

- каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм утильләштерү өчен кирәкле төзелеш материалы, инвентарь һәм җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарга, килешү буенча штаттан тыш хезмәт хакына-40 сум.

- зиратларны тотуга( төзелеш материаллары сатып алуга , килешү буенча хезмәт хакы алуга һ. б.) бәйле чыгымнарга -50 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Борискино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Борискино авыл җирлеге башлыгы: Г. В. Самарина.